# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“24” ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 23 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта, 2019 елның 24 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Чишмәле Сап авылында кое ремонтына төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү;

2) күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:
- Чишмәле Сап авылында зиярат коймаларын ремонтлау өчен төзү материаллары алу;

3) физкультура һәм массакүләм спортны үстерү:
- Чишмәле Сап авылында спорт мәйданчыгынын коймасын тотуга төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 225 (ике йөз егерме биш) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан граҗданнар саны 148 (бер йөз кырык сигез) кеше, бу 66 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 148 (бер йөз кырык сигез) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2020 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Чишмәле Сап авылында кое ремонтына төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү;

2) күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:
- Чишмәле Сап авылында зиярат коймаларын ремонтлау өчен төзү материаллары алу;

3) физкультура һәм массакүләм спортны үстерү:
- Чишмәле Сап авылында спорт мәйданчыгынын коймасын тотуга төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.

Совет Новошашинского сельского поселения
Яңа Шашы авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000765